| Республика Татарстан<br>Совет Верхне-Чершилинского<br>сельского поселения<br>Сармановского муниципального<br>района | | Татарстан Республикасы<br>Сарман муниципаль районының<br>Югары Чыршылы авыл<br>жирлеге Советы |
| --- | --- | --- |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

06 август 2019 ел Югары Чыршылы авылы №10

Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 17 нче сентябрендә кабул ителгән Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында"гы 15нче номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 1 маендагы 87-ФЗ номерлы Федераль закон» , Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының"Югары Чыршылы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль Югары Чыршылы авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ :

1. Югары Чыршылы авыл җирлеге Советының 2018 нче елның 17 нче сентябрендә кабул ителгән "Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге территориясендә гражданнар җыенын үткәрүгә әзерлек тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында" гы 15нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:
1) 4 бүлекнен 4.1.пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.Гражданнар җыены анда торак пункт яки җирлек халкының сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашында хокуклы. Торак пунктта әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган кешеләрнең яртысыннан артыгы бер үк вакытта бергә булу мөмкинлеге булмаса, күрсәтелгән торак пункт кергән муниципаль берәмлек уставы нигезендә гражданнар җыены этаплап, гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган срокта үткәрелә. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә алдагы этапларда катнашмый. Гражданнар җыены карары, әгәр аның өчен гражданнар җыенында катнашучыларның яртысыннан артыгы тавыш бирсә, кабул ителгән дип санала.».
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Югары Чыршылы авыл җирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга, шулай ук аны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" (PRAVO) TATARSTAN.RU («Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Сарман муниципаль район Югары Чыршылы авыл җирлеге
Советы рәисе И.Н.Камалетдинов